**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

29.12.2018 №600

"Юридик затларга (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга-товар җитештерүчеләргә, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 ел № 880 “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына таянып **КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 05. 31. 2018 ел 227 номерлы "Юридик затларга, дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләрдән тыш, субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә

Башкарма комитет җитәкчесе И. Н. Шәйдуллин